Раслыйм

Казан Казан шәһәре Мәскәү районының
КФУ каршындагы 2 нче татар
гимназиясе директоры

_____________ Р.Р.Гайнуллин

28 август, 2023 ел

Казан шәһәре Мәскәү районының
КФУ каршындагы 2 нче татар гимназиясенең
мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен төркемнәренең
**2023-2024 нче уку елына эш планы**

Педагогик берләшмә
утырышында кабул ителде
протокол №1
28 авгу, 2023 ел

# Мәгълумати белешмә.

Казан шәһәре Мәскәү районының КФУ каршындагы 2нче татар гимназиясенең мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен төркемнәре 420095, Казан шәһәре, Ш.Усманов урамы 11 Г адресы буенча урнашкан.

Балалар бакчасы заманча проект буенча төзелгән, 3 этажлы санитар-гигиеник һәм янгынга каршы таләпләргә туры килә торган кирпеч бинага урнашкан. Табигый һәм махсус ясалма яктырту нормаларга җавап бирә.

Балалар бакчасы 120 урынга исәпләнгән, 6 төркем эшли, бүгенге көндә җыелган балалар саны 160.

6 төркемнең:

1 төркем — 3 -4 яшьлек балалар

2 төркем — 4 -5 яшьлек балалар

1 төркем- 5-6 яшьлек балалар

1 төркем — 5-7 яшьлек балалар

1 төркем – 6-7 яшьлек балалар

2022– 2023 нче уку елында 14 педагог эшләде. Шуларның:

9 тәрбияче, 5 белгеч:

- муз. җитәкчесе
- укытучы -логопед
- педагог- психолог
- 2 физик культура инструкторы

Педагогик коллектив тулысынча педагогик белемгә ия.

Югары белем — 12 педагог- 86%

Махсус урта белем — 2 педагог- 14%

# 2022 – 2023 нче уку елына анализ

Балалар бакчасының эшчәнлеге түбәндәге норматив – хокукый документлар нигезендә билгеләнә:

- РФ конституциясе
- РФ Мәгариф турында законы
- Балалар хокуклары конвенциясе
- Устав
- Федераль дәүләт стандартлары

Балалар бакчасының белем бирү программасы, гимназиянең 2021-2026 нчы елларга Үсеш программасы буенча ел дәвамында балаларга мәктәпкәчә белем алуга уңайлы шартлар һәм мөмкинлекләр булдыру өстендә эш алып барылды. Хәзерге көндә балалар бакчасының программасын яңа шартларда федераль программага туры китереп төзү өстендә эш бара.

Педагогларның күбесе балалар бакчасында яңа эшли башлаучы белгечләр булу сәбәпле, квалификация категорияләрне арттыру өстендә даими эш алып барыла. Уку елы дәвамында 3 педагог 1нче квалификация категориясенә аттестация уздылар.

| Уку елы | 1 квалификация категориясе | югары квалификация категориясе |
|---|---|---|
| 2020-2021 | 56% | 6% |
| 2021-2022 | 50% | 8% |
| 2022-2023 | 66% | 8% |

2023-2024 нче уку елында яңадан 2 педагог 1нче квалификация категориясе алу буенча, 2 педагог югары категориягә аттестация үтәргә планлаштыралар.

Педагогларның һөнәри компетентлыкларын үстерү 2022-2023 нче уку елының төп бурычларыннан берсе иде. Шуңа күрә бу юнәлештә эш ел буе алып барылды. Уку елы дәвамында 2 педагог квалификация үстерү курслары уздылар (Давлетшина Г.Н., Сибагатова А.Д.)

Педагоглар белем һәм тәҗрибә туплау һәм уртаклашу максатыннан даими рәвештә төрле семинар-практикумнарда катнашып торалар.

**Семинар-практикумнарда катнашу**

| Катнашучылар категориясе | катнашучы | Чыгыш | Уздыру вакыты |
|---|---|---|---|
| Район Татар теленә өйрәтү тәрбиячеләре өчен методик берләшмә, 105 нче балалар бакчасы | Әхмәтгалиева М.Р. | “Әкиятләр илендә” проекты кысаларында балаларның сөйләм телен үстерү | 2022, ноябрь |
| Чувашия Республикасыннан килгән татар теле укытучылары өчен семинар | Шәрәфиева Р.Р. | Формирование единой образовательной среды в ДОУ как основа для развития природных возможностей дошкольников | 2022, ноябрь |
| Балалар бакчасы мөдирләре өчен республика семинары | Мустафина Г.Н, Ибраһмиова Л.Ф. | 1.Использование СМИ для творческого развития детей.<br>2.Развитие творческих способностей детей дошкольного возраста средствами музыкально- | 2022, декабрь |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | драматического искусства. | |
| Школа молодого педагога-психолога ДОО в ДОУ №133 | Иштуганова З.Р. | Снятие эмоционального выгорания с помощью игр. | 2023, февраль |
| Татар төркеме тәрбиячеләре өчен семинар-практикум, 417 нче балалар бакчасы | Иштуганова З.Р. | А.Алиш әкиятләре аша балаларның сөйләм телен һәм логик фикерләвен үстерү | 2023, апрель |
| Район музыка җитәкчеләре семинар-практикумы, 122 нче балалар бакчасы | Ибраһимова Л.Ф. | Түгәрәк уеннары буенча мастер-класс | 2023, май |

**Педагогларның конкурсларда катнашулары нәтиҗәләре**

| Конкурс исеме | нәтиҗәләр |
|---|---|
| Районный конкурс «Книга своими руками «Современный взгляд на произведения С.Я.Маршака», Ахметгалиева М.Р., Губайдуллина Г.А., Шарипова А.Г., Гимадиева Г.М., Иштуганова З.Р., Нигматуллина А.Ф., Сибагатова А.Д. | 3 урын |
| Районный конкурс «Книга своими руками «Современный взгляд на произведения Э.Н.Успенского», Ахметгалиева М.Р., Губайдуллина Г.А., Шарипова А.Г., Гимадиева Г.М., Давлетшина Г.Н., Сибагатова А.Д. | 3 урын |

| | |
|---|---|
| Районный конкурс «Книга своими руками «Современный взгляд на произведения татарских поэтов и писателей», Ахметгалиева М.Р., Губайдуллина Г.А., Шарипова А.Г., Гимадиева Г.М., Давлетшина Г.Н., Сибагатова А.Д. | 1 урын |
| Районный этап городского конкурса «Давайте познакомимся: дошкольное образование г.Казани», Накипова Н.Г., Шарафиева Р.Р. | 3 урын |
| Городской конкурс «Давайте познакомимся: дошкольное образование г.Казани», Накипова Н.Г., Шарафиева Р.Р. | 3 урын |
| Районный конкурс «Лучшая интерактивная игра для детей дошкольного возраста» | «Лучшая интерактивная игра» Номинациядә җиңүче |

**Балалар белән эшнең нәтиҗәлелеге**

| Чараның исеме | нәтиҗә |
|---|---|
| Районный этап городского конкурса чтецов «Звездный билет», Абрахимов Абдулсамат | 2 урын |
| Международный конкурс-фестиваль «Илһамият-VIII», Кадырова Нафиса | 3 урын |
| Районный этап городского конкурса «Татар малае-2023, Татар кызчыгы-2023», Әхәтов Хәлид, Зиннурова Зифа | 1 урын,<br>Гран-при |
| Городской этап конкурса Татар кызчыгы-2023», Зиннурова Зифа | лауреат |
| Городской фестиваль национальных культур «Алтын сәгать», коллективы «Кояш | 2,3 урын |

| | |
|---|---|
| нурлары», «Балачак», Кадырова Нафиса | |
| Районный конкурс «Туган тел», Кадырова Нафиса | 1 урын |
| Районный этап городского фестиваля-конкурса «Балачак иле», Гатина Саида | 1 урын |
| «Илһам чишмәсе» исемедәге 3нче төбәкара җыр бәйгесе, Гатина Саида | 3 урын |
| Халыкара туган тел көнендә “Туган телем” дип исемләнгән халыкара конкурс Кадырова Нәфисә | 2 урын |
| Республиканский творческий конкурс «В созвездии А.С.Пушкина и Г.Тукая», Валиахметов Нияз | 3 урын |
| «Умка», «Умный мамонтенек», Межрегиональные очные олимпиады ЦСГО «Микс по математике», «Задачи», «Живая и неживая природа», Әмирханов Камил, Минкина Диләрә, Шакирова Диана | Гран-при, 2-3 урыннар |

Милли балалар бакчасында туган телне үстерү һәм саклау, татар телендә балаларның сөйләмен үстерү өстендә эшләү, балаларга милли тәрбия бирү безнең коллектив өчен иң мөһим бурыч.

Уку елы дәверендә тәрбиячеләр балалар белән «Туган телдә сөйләшәбез» кулланмасы буенча шөгыльләнделәр.

Балаларны татар халык һәм заманча авторлар әкиятләре аша туган телгә өйрәтү буенча «Әкиятләр илендә» методик кулланмасы буенча ел дәвамында балалар белән әкиятләр уку һәм сәхнәләштерү буенча эш оештырылды. Әлеге проектны уңышлы дип әйтә алабыз, балаларның сөйләм теле матурая, чистара. Балалар төрле сәнгатьле сөйләм конкурсларында уңышлы чыгыш ясыйлар. (Кадырова Нәфисә, Минкина Диләрә, Вәлиәхмәтов Нияз һ.б). Мәктәпкә әзерлек төркеме балалары белән әзерләнгән «Тылсымлы алма»

әкияте Сәйяр театр фестиваленең район турында беренче урын алып республика турына узды, финалга узган 100 театр исемлегенә керде.

Туган телне үстерү һәм телгә мәхәббәт тәрбияләүдә тәрбияче факторы да зур урын алып тора. Тәрбиячеләр Мостафина Г.Н., Накыйпова Н.Г, Гыймадиева Г.М., Әхмәтгалиева М.Р., Ибраһимова Л.Ф. балаларның туган телдә аралашуы өчен барлык шартларны тудырырга тырышалар, туган телгә өйрәтүнең төрле алымнарын кулланалар. 2022 нче ел Республикада Халыклар милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр еллыгы дип игълан ителде. Бакчада башкарылачак тематик чараларның планы төзелде. Шул план нигезендә төркемнәр арасында татар халык уеннары һәм бармак уеннары буенча үзара ачык шөгыльләр карау оештырылды, ел дәвамында төрле темаларга шигырь сөйләүчеләр бәйгеләре уздырылды.

Балалар белән эш күрсәткечләре ел башында һәм ел ахырында тикшерелде.

«Туган телдә сөйләшәбез» методик кулланмасы буенча барлык төркемнәрнең уртача нәтиҗәләре түбәндәгечә булды:

| Төркемнәр | Югары дәрәҗәдә | Уртача дәрәҗәдә | Түбән дәрәҗәдә |
|---|---|---|---|
| Кечкенәләр №1 | 32% | 64% | 5% |
| Кечкенәләр №3 | 41% | 54% | 5% |
| Уртанчылар №4 | 26% | 60% | 0% |
| Зурлар №5 | 80% | 20% | 0% |
| Катнаш №2 | 55% | 40% | 5% |
| Мәктәпкә әзерлек №6 | 94% | 6% | 0% |
| **Гомуми нәтиҗә** | **55%** | **42%** | **3%** |

«Изучаем русский язык" методик кулланмасы буенча татар балаларының рус телен белү дәрәҗәсе:

| Төркемнәр | Югары дәрәҗәдә | Уртача дәрәҗәдә | Түбән дәрәҗәдә |
|---|---|---|---|
| Уртанчылар (4) | 74% | 26% | 0% |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Катнаш (2) | 79% | 21% | 0% |
| Зурлар (5) | 76% | 23% | 0% |
| Мәктәпкә әзерлек төркеме (6) | 77% | 23% | 0% |
| **Уртача нәтиҗә** | **77%** | **23%** | **0%** |

Күрсәткечләрне тагын да яхшырту өчен, ата-аналар һәм балаларны туган телне өйрәнүгә тарту өчен түбәндәгеләрне планлаштырабыз:

- Башка милләттән һәм катнаш гаиләләрдән булган балалар һәм ата-аналарда да татар теленә хөрмәт һәм татар телен өйрәнүгә кызыксындыру тудыру максатыннан ата-аналар өчен туган телне саклау һәм үстерү турында консультацияләр, бәйрәмнәр һәм күңел ачу чаралары уздыру.
- Бакчага йөрмәүче балалар һәм аларның ата-аналары өчен туган телне өйрәтү курслары оештыру.
- Балаларны туган телләрендә һәм икенче дәүләт телендә өйрәтү өчен яңа укыту-методик кулланмалар һәм яңа алымнар куллану.
- Туган телдә узган бәйрәм чараларында, конкурсларда, телевизион тапшыруларда катнашу.
- Гимназиянең “Татарча он-лайн мәктәп” проектында катнашуны дәвам итү.

Балалар бакчасының тәрбия һәм белем бирү юнәлешләренең берсе булып балаларда сөйләм кимчелекләрен төзәтү тора. Узган уку елында балалар бакчасында балалар белән укытучы- логопед Л.Ф. Салаватуллина, Д.М.Әхмәдиева, тәрбиячеләр Н.Г.Накыйпова, А.Д.Сибагатова, А.Ф.Нигматуллина шөгыльләнделәр. ПМПК карары нигезендә, логопедия төркеменә 8 бала кабул ителде, логопедия төркеменнән 6 бала чыгарылды: 4 бала чиста сөйләм белән, 2 бала сизелерлек үзгәрешләр белән мәктәпкә чыгарылдылар. Елдан-ел балалар арасында логопед ярдәменә мохтаж балалар саны артуы күзәтелә. Без моның сәбәпләрен балалар белән аз

аралашу, күбрәк телевидение һәм компьютер йогынтысыннан күрәбез. Быелгы уку елына җыелган балалар саны 13 булды.

Гимназия белән хезмәттәшлек ел дәвамында барды. Гимназиядә уздырылган педагогик киңәшмәләрдә, Белем көнендә катнаштык. Г.Тукай әсәрләренә рәсемнәр күргәзмәсендә, Пушкин мәктәбендә, «20нче гасыр кайтавазы» музейларында булдык.

Уку елы дәверендә 2 тематик, 1 комплекслы тикшерү уздырылды.

22.08.2022 ел, Приказ №6 нигезендә

Үткәрү вакыты: 22-28 нче август- 2022

Максаты: Балалар бакчасында төркемнәрнең һәм кабинетларның яңа уку елына әзерлеген тикшерү.

Тикшерү түбәндәге юнәлешләр буенча алып барылды:

- Төркемнәрнең һәм кабинетларның матераиль-техник базасы;
- Төркемнәрдә һәм кабинетларда ата-аналар өчен почмаклар торышы;
- Балалар белән эшне планлаштыру;
- Төркемнәрдә һәм кабинетларда документларның торышы;
- Санитар- гигиеник таләпләрнең үтәлеше;
- Балаларның тормыш иминлеген тәэмин итү.

Нәтиҗәләр:

- Төркемнәрнең һәм кабинетларның матераиль-техник базасы уку елына әзерлек буенча кәнәгатьләнерлек торышта дигән нәтиҗәләр ясалды.
- Ата-аналар өчен почмаклар яңа уку елы өчен яңартылган. Балаларның белем бирүен оештыру, көндәлек режим, ата-аналар өчен киңәшләр зәвыклы һәм ата-аналар өчен уңайлы итеп урнаштырылган.
- Төркемнәрдә балалар белән һәр төрле эшчәнлек өчен шартлар тудырылган.

Киңәшләр:

- Тәрбиячеләргә үзбелемнәрен күтәрүөстендә даими эш алып барырга;
- Барлык документларны билгеле бер урында, бер папкада сакларга;

- Зурлар, уртанчылар төркемендә яшь үзенчәлекләренә туры килгән дидактик уеннарны арттырырга.
- Балалар өчен уен һәм уенчыкларны балалар өчен уңайлы югарылыкта саклауны һәм урнаштыруны оештырырга.

2. 2нче татар гимназиясенең мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен төркемнәрендә спорт почмакларының торышын тематик тикшерү

Приказ №4,13.02.2023 ел. Тикшерү вакыты- 13-17 февраль

Тикшерү түбәндәге юнәлешләр буенча алып барылды:
- Сәламәтлекне саклау
- Почмакның паспорты һәм эш планы булуы; урыны, балалар өчен уңайлылыгы.
-Балаларны чыныктыру
-Хәрәкәт эшчәнлеге өчен уңай шартлар тудыру
-әти-әниләр өчен мәгълумат
-Балалар белән шәхси эш оештыру
-Гадәти булмаган чыныктыру һәм уен чаралары кулланyГадәти булмаган чыныктыру һәм уен чаралары куллану

Тикшерү нәтиҗәләре буенча эш торышы кәнәгатьләнерлек дип табылды. Эш системалы рәвештә алып барыла, балалар яшь үзенчәлегенә туры килгән сорауларга дөрес җаваплар бирәләр, биремнәрне теләп үтиләр. Тәрбиячеләр барысы да спорт почмакларының яшь үзенчәлекләренә туры китерелгән һәм күрсәтмә материалларның җитәрлек күләмдә булуына ирешергә тырышалар. Мәктәпкә әзерлек төркемнәрендә, уртанчылар төркемендә җитәрлек күләмдә методик һәм дидактик материал тупланган.

Киңәшләр:

- Балалар белән су процедуралары уздыру буенча киңәшләр әзерләргә ( 2, 4).
- Хәрәкәтле уеннар каталогын төзергә;
-Саф һавада хәрәкәтле уеннарны төгәл планлаштырырга;
- Төркемнәрдә хәрәкәт эшчәнлеге үзәкләрен тулыландырыга.
- Төркем бүлмәсен җилләтү графикларын булдырырга (№1, 2, 4,5).

-Балалар белән сәламәт яшәү рәвеше, дөрес туклану,бердәмлек көче турында әкиятләр укырга.

-Әти-әниләр өчен физик тәрбия инструкторы киңәшләре папкасы булдырырга.

Мәктәпкә әзерлек төркемендә апрель аенда 03.04.2023 елгы №6 боерык нигезендә комплексды тикшерү үткәрелде.

6 нчы төркемнең тәрбиячеләре Сибагатова Алия Дамировна, Давлетшина Гүзәлия Назимовна, тәрбияче ярдәмчесе Гарифуллина Лилия Камиловна. Төркемдә 30 бала йөри.

Тикшерү объектлары: тәрбиячеләрнең эш планнары һәм документациянең торышы, төркемнәрнең үсеш тирәлеге, профилактик чыныктыру чаралары уздыру, балалар белән шәхси эш оештыру, тәрбиячеләрнең балалар белән уртак эшчәнлеге, төркемдә психологик климат, балаларның мәктәпкә әзерлеге, уеннар оештыру, ата-аналар белән эшнең торышы.

Тикшерүдән соң төркемнең эшчәнлеге кәнәгатьләнерлек дип табылды.
Тикшерү ахырында бирелгән киңәшләр:

- Тәрбиячеләргә үз эшләрендә күбрәк заманча технологияләр кулланырга;
- Балалар бакчасының белем бирү программасында федераль дәүләт таләпләре буенча каралган барлык өлкәләрне тормышка ашыру буенча перспектив планнар һәм проектлар төзергә һәм туплауга игътибарны арттырырга;
- Балаларның танып белү эшчәнлеге, эксперименталь эшчәнлек өчен материалны арттырырга кирәк;
- Балалар белән шәхси эш, чыныктыру процедуралары, саф һавада уеннар оештыруга күбрәк вакыт сарыф итәргә киңәш бирелде.

Оператив контроль «Туган җирем- Татарстан» почмакларының торышы», «Уен мәйданчыкларының кышкы чорга әзерлеге», «Төркемнәрне җилләтү, җыештыруның торышы», «Ата-аналар белән эшнең торышы», «Балаларның туклануын оештыру», «Иртәнге гимнастика үткәрү»,

«Төркемнәр һәм мәйданчыкларның җәйге чорга әзерлеге» темалары буенча уздырылды.

Балалар бакчасында балаларның сәламәтлеген саклау- мөһим бурычларыбызның берсе. Бу уку елында «Балаларның сәламәт тукклануы» федераль программасы кысаларында бакчаның 10 тәрбиячесе курслар уздылар һәм балаларның дөрес туклануын оештыру, өйрәтү өстендә эшлиләр. Шулай ук берничә әти-әни дә әлеге чарада актив катнашып, балалар белән дөрес туклану программасы өстендә эшлиләр. Мәктәпкәчә яшьтәге балаларның дөрес туклануы нормаль физик үсешенә зур йогынты ясый һәм ул дөрес оештырылырга тиеш.

Ел дәвамында азык-төлек департаменты тәкъдим иткән 10 көнлек меню буенча да эш алып барылды. Департамент тарафыннан тикшерү уздырылды, туклану бүлегендә кимчелекләр табылмады.

Бер баланың ел буена авырып калдырган көннәр саны аз булса да (ел буена бер балага якынча 4 көн), балаларның бакчада уртача йөреше 70% тәшкил итә. Балаларның күбесе күпбалалы гаиләләрдән, әниләрнең күбесе икенче-өченче балалары белән ялда утыра, шуңа күрә һәркөнне баланы бакчага китерергә мөмкинчелек тапмыйлар. Ел дәвамында әти-әниләр белән бакчага даими йөрү баланың бакчага ияләнүе, үсеше өчен мөһим булуын аңлату өстендә эш алып бардык.

Балалар бакчасы коллективы 2022-2023 нче уку елында расланган план буенча эш алып барды. Планда балаларның һәрьяклы шәхси үсеше өчен индивидуаль үзенчәлекләре исәпкә алынды. Узган елга йомгак ясап, коллектив куелган максатларны өлешчә үтәде дип әйтә алабыз һәм түбәндәге нәтиҗәләрне чыгарабыз:

- Балалар бакчасында уздырылган чаралар аша балаларның туган телләрендә сөйләм телен үстерү буенча эш алып барылды;
- Федераль дәүләт программасына нигезләнеп балалар бакчасының белем бирү программасын төзү буенча норматив документлар өйрәнелде.

- Педагогларның педагогик сәләтләрен, эшкә мөнәсәбәтләрен һәм белем, күнекмәләрен төрле конкурслар һәм ярышларда катнашу, үзбелемнәрен арттыру аша башкарылды.

Административ - хуҗалык эшләре план буенча уздырылды:

1. Уен мәйданчыклары тәртипкә китерелде.
2. Методик әдәбият, күрсәтмә материаллар тупланды.
3. Төркемнәрдә түшәмнәргә косметик ремонт ясалды.

Балалар бакчасының киләчәктәге перспективалары:

- Туган телне саклау һәм үстерү:
- Ата-аналарның балаларына туган телдә мәктәпкәчә белем бирүгә теләкләрен кәнәгатьләндерү;
- Баланың шәхесенә үзен җәмгыятьтә иркен тотарга ярдәм итү, үз халкына һәм башка милләтләргә ихтирамлы караш тәрбияләү;
- Мәктәпкә барыр өчен физик яктан сәламәт балалар тәрбияләү.
- Балаларның иҗади сәләтләрен үстерү;
- Гимназия белән хезмәттәшлекне ныгыту.

Әлеге юнәлешләрне тормышка ашыруның юлы түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

- Педагогларның профессиональ үсешен булдыру;
- Ата-аналарны кызыксындыру, туплау;
- Алда әйтелгән максатларны тормышка ашыру өчен шартлар булдыру;
- Балалар өчен түләүле белем бирү хезмәтләре тәкъдим итү.

2022-2023 нче елда куелган бурычларны анализлап, куелган максатлар расланган план буенча үтәлде дип әйтергә була һәм шулардан чыгып

**2023-2024 нче елның бурычларын** билгелибез:

1. Балалар бакчасында федераль дәүләт стандартларын һәм федераль программага нигезләнеп балалар бакчасының белем бирү программасын тормышка ашыру.

2. Балаларның ике дәүләт телендә аралашуын яхшырту, педагогларның профессиональ компетентлыкларын үстерү, балалар бакчасы һәм

гимназия арасындагы күчүчәнлекне тәэмин итү буенча гимназиянең башлангыч сыйныф укытучылары белән хезмәттәшлекне дәвам итү.

3. Балаларның тормыш иминлеген тәэмин итү.

Сентябрь

| № | Эшнең эчтәлеге | Вакыты | Җаваплы кеше |
|---|---|---|---|
| 1. | Төркемнәрнең яңа уку елына әзерлеген тематик тикшерү | 1 нче атна | Р.Р.Шәрәфиева, комиссия |
| 2. | Педагогик киңәшмә уздыру «2023-2024 нче уку елына гимназиянең төп бурычлары һәм юнәлешләре» | 1 нче атна | Р.Р.Гайнуллин |
| 3. | Гимназиядә уздырылган «Белем бәйрәме»ндә катнашу | 1 нче атна | Давлетшина Г.Н. |
| 4. | Әти-әниләр өчен киңәш «Балаларның мәктәптә укуга әзерләү» | 3 нче атна | З.Р.Иштуганова |
| 5. | «Балалар бакчасында федераль дәүләт стандартларын һәм федераль программага нигезләнеп балалар бакчасының белем бирү программасын тормышка ашыру» педагоглар өчен консультация | 2нче атна | Р.Р.Шәрәфиева |
| 6. | «Минем яраткан уеннарым һәм уенчыкларым!» Балалар рәсемнәре күргәзмәсе | 3 нче атна | Иҗади төркем |
| 7. | Балаларның өстәмә шөгыльләргә йөрүен оештыру | 2 нче атна | Р.Р.Шәрәфиева |
| 8. | Саф һавада уен-шөгыль «Без-җәяүлеләр» | 3нче атна | А.Ф.Нигматуллина |
| 9. | Спорт мәйданында «Күңелле стартлар» | 2 нче атна | Б.Г.Хәбибуллин |

Октябрь

| № | Эшнең эчтәлеге | Вакыты | Җаваплы кеше |
|---|---|---|---|
| 1. | Өлкәннәр көне уңаеннан чаралар уздыру | 1 нче атна | Л.Ф.Ибраһимова |
| 2. | Тәрбиячеләр өчен консультация «Балаларга шигырь сөйләргә һәм хикәя төзергә өйрәтү технологияләре» | 2 нче атна | Д.М.Әхмәдиева |
| 3. | Ата-аналар өчен консультация «Балаларның сүзлек байлыгын үстерү өчен уеннар» | 3 нче атна | З.Р.Иштуганова |
| 4. | Тәрбиячеләрнең методик берләшмәсе утырышы «Балаларның сөйләмен үстерү буенча заманча технологияләр» | 3 нче атна | Иҗади төркем |
| 5. | Төркемнәрдә ата-аналар очрашулары | 1 нче атна | Төркем тәрбиячеләре |
| 6. | Төркемнәр арасында конкурс «Сюжетлы-рольле уеннар» | 4 нче атна | М.Р.Әхмәтгалиева |
| 7. | Оператив тикшерү «Туган җирем – Татарстан» почмакларының торышы | 3 нче атна | Комиссия |
| 8. | «Минем яраткан әби-бабаем» балалар рәсемнәре конкурсы | 1 нче атна | Иҗади төркем |
| 9. | Гимназия китапханәсенә экскурсия оештыру | 3 атна | Мәктәпкә әзерлек төркеме тәрбиячеләре |
| 10. | «Алтын көз» ( көз бәйрәмнәре уздыру) | 4 атна | Л.Ф.Ибрагимова |

Ноябрь

| № | Эшнең эчтәлеге | Вакыты | Җаваплы кеше |
|---|---|---|---|
| 1. | Тәрбиячеләр өчен консультация «Сөйләм үсеше өчен дидактик уеннар әзерләү» | 1 нче атна | А.Ф.Нигматуллина |
| 2. | Күзгә шигырь сөйләүчеләр бәйгесе | 3 нче атна | М.Р.Әхмәтгалиева |
| 3. | Тәрбиячеләрнең методик берләшмәсе утырышы «Балаларның танып-белү эшчәнлеген оештыруда яңа алымнар һәм технологияләр» | 4 нче атна | Р.Р.Шәрәфиева |
| 4. | Ата-аналар өчен консультацияләр<br>- «Салкын тию авыруларын кисәтү»<br>- «Саф һавада йөрүне файдалы итеп оештырыйк» | 3 нче атна | Г.А.Губайдуллина |
| 5. | Балалар рәсемнәре күргәзмәсе «Минем яраткан әнием» | 4 нче атна | Иҗади төркем |
| 6. | Әниләр көненә багышланган чаралар уздыру | 4 нче атна | Иҗади төркем |
| 7. | Тематик тикшерү «Төркемнәрдә уен үзәкләре» | 2 нче атна | Комиссия |
| 8. | Гимназиядә узучы «Татар халык җырлары»фестивалендә катнашу | | |

Декабрь

| № | Эшнең эчтәлеге | Вакыты | Җаваплы кеше |
|---|---|---|---|
| 1. | Төркемнәрдә юл иминлеге почмаклары арасында смотр-конкурс | 2-3 нче атна | комиссия |
| 2. | Оператив тикшерү «Мәйданчыкларның кышкы чорга әзерлеге» | 1 нче атна | комиссия |
| 3. | Кышкы мәйданчыклар конкурсында катнашу | 3 нче атна | Иҗади төркем |
| 4. | Хезмәткәрләр арасында яңа ел бәйрәмен уздыру буенча инструктаж үткәрү | 3 нче атна | Р.Р.Шәрәфиева |
| 5. | Ата-аналар өчен консультация «Кышкы ялларны файдалы һәм күңелле үткәрик» | 2 нче атна | А.Д.Сибагатова |
| 6. | «Әти, әни, мин-музыкаль гаилә» (мәдәни мирас елы) | 2 нче атна | Л.Ф.Ибрагимова |
| 7. | Балалар рәсемнәре күргәзмәсе «Яңа елны көткәндә» | 4 нче атна | Иҗади төркем |
| 8. | Яңа ел бәйрәменә чаралар уздыру | 4 нче атна | Иҗади төркем |
| 9. | Тәрбиячеләр өчен консультация «Тәрбиясенең һәм ана-аналарның бала тәрбияләүдә тоткан урыны» | 1 нче атна | Р.Р.Шәрәфиева |

Январь

| № | Эшнең эчтәлеге | Вакыты | Җаваплы кеше |
|---|---|---|---|
| 1. | Салкын тию авыруларын кисәтү буенча чаралар уздыру | 1-2 нче атна | Шәфкать туташы |
| 2. | Тәрбиячеләр өчен консультация «Аз аралашучан балалар белән эшләү» | 1 нче атна | З.Р.Иштуганова |
| 3. | Ата-аналар өчен консультация: «Балаларның сәнгать эшчәнлеген оештыру» «Мәктәпкәчә яшьтәге бала үсешендә китапның урыны» | 1 нче атна | Л.Ф.Ибраһимова А.Г.Шарипова |
| 4. | Оператив тикшерү «Бүлмәләрне җилләтү, җыештыруның торышы» | 3 нче атна | Шәфкать туташы |
| 5. | «Кышкы матурлык» балалар рәсемнәре күргәзмәсе | 3 нче атна | Иҗади төркем |
| 6. | Төркемнәр арасында иң яхшы үсеш тирәлеген оештыру буенча конкурс | 4 нче атна | Комиссия |
| 7. | Баларның сөйләм телен үстерү эшчәнлеген оештыру (ачык оештырылган белем бирү эшчәнлеге карау) | 4 атна | Педколлектив |

Февраль

| № | Эшнең эчтәлеге | Вакыты | Җаваплы кеше |
|---|---|---|---|
| 1. | Тәрбиячеләр өчен консультация «Спорт һәм сәламәтлек почмакларында атрибутлар һәм уеннар» | 3 нче атна | Халимова З.Ф., Хабибуллин Б.Г. |
| 2. | Ата-аналар өчен киңәш: «Һәр яшь төркеме өчен файдалы уеннар һәм уенчыклар» | 2 нче атна | Г.М.Гыймадиева |
| 3. | Ватанны саклаучылар көне уңаеннан чаралар уздыру. | 3-4 нче атна | Л.Ф.Ибраһимова |
| 4. | Тематик тикшерү «Төркемнәрдә юл иминлеге почмаклары торышы» | 3нче атна | Комиссия |
| 5. | «Минем яраткан әтием» балалар рәсемнәре күргәзмәсе | 3 нче атна | Иҗади төркем |
| 6. | Туган тел көне уңаеннан чаралар уздыру | 4 нче атна | Иҗади төркем |
| 7. | Оператив тикшерү «Ата-аналар белән эшнең торышы» | 4 нче атна | Иҗади төркем |

Март

| № | Эшнең эчтәлеге | Вакыты | Җаваплы кеше |
|---|---|---|---|
| 1. | 8 Март бәйрәме уңаеннан чаралар оештыру | 2 нче атна | Л.Ф.Ибраһимова |
| 2. | Язгы «Күңелле стартлар» спорт бәйрәме оештыру | 4 нче атна | Б.Г.Хәбибуллин |
| 3. | Нәүрүз бәйрәме үткәрү | 3 нче атна | Иҗади төркем |
| 4. | Ата-аналар арасында анкета уздыру «Балалар бакчасы тәкъдим иткән хезмәтләр белән канәгатьлекне ачыклау» | 2 нче атна | Р.Р.Шәрәфиева |
| 5. | Тәрбиячеләр өчен консультация «Мониторинг уздыруга әзерләнү» | 1 нче атна | Р.Р.Шәрәфиева, З.Р.Иштуганова |
| 6. | Ата-аналар өчен консультация «Балаларда мөстәкыйльлек тәрбияләү» | 3 нче атна | А.Д.Сибагатова |
| 7. | Оператив тикшерү «Төркемнәрдә иртәнге гимнастика үткәрү» | 1 нче атна | Р.Р.Шәрәфиева |
| 8. | Балалар рәсемнәре күргәзмәсе «Минем яраткан әнием» | 1 нче атна | Иҗади төркем |
| 9. | Төркемнәр арасында иң яхшы табигать почмагын ачыклау буенча конкурс | 4 нче атна | Комиссия |

Апрель

| № | Эшнең эчтәлеге | Вакыты | Җаваплы кеше |
|---|---|---|---|
| 1. | «Мәктәпкәчә яшьтәге балаларның сөйләм үсеше» район методик берләшмәсен кабул итү | 2 нче атна | Р.Р.Шәрәфиева, М.Р.Ахметгалиева |
| 2. | Ата-аналарның гомуми җыелышы | 3 нче атна | Р.Р.Шәрәфиева |
| 3. | Төркемнәрдә ата-аналар очрашулары уздыру | 3 нче атна | Төркем тәрбиячеләре |
| 4. | Төркем тәрбиячеләренең иҗади отчеты | 2 нче атна | Р.Р.Шәрәфиева |
| 5. | Мәктәпкә әзерлек төркемендә комплексла тикшерү үткәрү | 1 нче атна | Комиссия |
| 6. | Ата-аналар өчен консультация «Яшь үзенчәлекләренә туры китереп, балаларга куркынычсызлык кагыйдәләрен өйрәтү» | 3 нче атна | З.Ф.Халимова |
| 7. | Бөтендөнья сәламәтлек көнен билгеләп үтү | 2 нче атна | Физинструктор |
| 8. | Балалар рәсемнәре күргәзмәсе «Спорт-сәламәтлекнең нигезе» | 1 нче атна | Иҗади төркем |
| 9. | Г.Тукайнын туган көне уңаеннан шигырь сөйләүчеләр конкурсы уздыру | 4 нче атна | Иҗади төркем |

Май

| № | Эшнең эчтәлеге | Вакыты | Җаваплы кеше |
|---|---|---|---|
| 1. | Педагогик киңәшмә «2023-2024 нче уку елына йомгак ясау, яңа уку елының бурычларын билгеләү» | 2 нче атна | Р.Р.Гайнуллин, Р.Р.Шәрәфиева |
| 2. | Җиңү көненә багышланаган чаралар уздыру | 1-2 нче атна | Л.Ф.Ибраһимова |
| 3. | Мониторинг уздыру | 2-3 нче атна | Төркем тәрбиячеләре |
| 4. | Мәйданчыкларны һәм төркемнәрне җәйге чорга әзерләү | 1-3 нче атна | Р.Р.Шәрәфиева |
| 5. | Тәрбиячеләр өчен консультация «Җәйге чорда саф һавада уеннар һәм күзәтәләр» | 1 нче атна | Г.М.Гобәйдуллина |
| 6. | Оператив тикшерү «Төркемнәр һәм мәйданчыкларның җәйге чорга әзерлеге» | 3 нче атна | комиссия |
| 7. | Юл йөрү кагыйдәләре буенча саф һавада күңел ачу чарасы | 4 нче атна | Иҗади төркем |
| 8. | Балалар рәсемнәре күргәзмәсе «Мин - тәртипле җәяүле» | 1 нче атна | Иҗади төркем |

Казан шәһәре Мәскәү районының
КФУ каршындагы 2 нче татар гимназиясенең
мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен төркемнәре

# 2023-2024 нче уку елына
# ата-аналар белән эш
# планы

2023 ел

## Мәгълумати өлеш

| № | Эшнең эчтәлеге | вакыты | җаваплы кеше |
|---|---|---|---|
| 1. | 2022-2023 нче уку елында башкарылан эшләргә нәтиҗә ясау | август | Р.Р.Шәрәфиева, ата-аналар комитеты җитәкчесе |
| 2. | «Төркемнәрнең һәм кабинетларның яңа уку елына әзерлеге. Яңа уку елына яңа бурычлар һәм максатлар» | октябрь | Р.Р.Шәрәфиева |
| 3. | «Ачык ишекләр көне» оештыру | октябрь апрель | Р.Р.Шәрәфиева,ата-аналар комитеты |
| 4. | Ата-аналар өчен түгәрәкләр эшчәнлеге нәтиҗәләрен күрсәтү | Апрель,май | Р.Шәрәфиева, ата-аналар комитеты |
| 5. | Ата-аналар өчен консультацияләр әзерләү һәм уздыру | Ел дәвамында | Иҗади төркем |
| 6. | Ярдәмгә мохтаҗ гаиләләргә педагогик һәм психологик ярдәм күрсәтү | Кирәк булганда | Тәрбиячеләр һәм махсус белгечләр |
| 7. | Балалар бакчасына яңа килүче кечкенә яшьтәге балаларның ата-аналары өчен адаптация курслары уздыру | август | Иҗади төркем |
| 8. | Ата-аналар өчен мәглумати стендлар урнаштыру | сентябрь | Иҗади төркем |

## Практик өлеш

| | | | |
|---|---|---|---|
| 1. | Ата-аналарны чакыру<br>• «Ачык ишекләр көне»;<br>• бәйрәм чаралары;<br>• концертлар һ.б.<br>• күргәзмәләр | план буенча | Бакча мөдире, Музыка җитәкчесе |
| 2. | Педагогик киңәшмәләрдә катнашу | план буенча | Бакча мөдире |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 3. | Ата-аналар өчен тематик консультацияләр оештыру | план буенча | Тәрбиячеләр |
| 4. | Төркемнәрдә ата-аналар очрашулары уздыру<br>• «Балаларның яшь үзенчәлекләре. Тәрбия һәм белем бирү бурычлары»<br>• Балалар белән уздырылган чараларның нәтиҗәләре» | октябрь<br><br><br><br>апрель | Тәрбиячеләр |
| 5. | Ата-аналарның гомуми җыелышын уздыру | ноябрь<br>май | Бакча мөдире, ата-аналар комитеты җитәкчесе |
| 6. | Балалар бакчасына яңа килүче кечкенә яшьтәге балаларның ата-аналары өчен адаптация курслары уздыру | август | Иҗади төркем |

Педагогик берләшмә
утырышында кабул ителде
Беркетмә №1 "28" август 2023 ел
Карар № 269 "28" август 2023 ел

«Раслыйм»
2нче гимназия директоры
__________ Р.Р.Гайнуллин

2023-2024нче уку елына

педагог-психологның перспектив планы

Педагог-психолог:

Иштуганова З.Р

Казан, 2023

Төп эш юнәлеше:

1. Диагностика
2. Балалар белән коррекцион-үсеш эше.
3. Консультация.
4. Әти-әниләрне балалар психологиясе белән таныштыру

**Психодиагностика**

| Категория | Эшнең эчтәлеге | Дәвамы |
|---|---|---|
